# Чишмә башы

## Гыйнвар, 2026

*Хөрмәтле хезмәттәшләребез*!

Яңа еллар котлы булсын!

**Яңа ел** барыбызга
Китерсен бәхет, шатлык.
Сәламәтлек юлдаш булсын!
Кирәкми башка затлык.
Тынычлык булсын илдә,
Елмайсын йөзләр гел дә!
Күк йөзендә кояш безгә,
Нурларын сипсен гел дә.
Эшләребез уң булсын,
Тик шатлыклы минутлардан
Безнең гомерләр торсын!
Яңа ел котлы булсын!




*Гыйнвар аенда гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтүче хезмәттәшләребез,укучыларыбыз!*

Йолдыздай җемелди ак
карлар,
Күмелә бар дөнья аклыкка.
Ак кыштa килгәнсез дөньяга
Әйләнеп өр-яңа шатлыкка.

Ак карлар, ак биләү, ак
шатлык…
Әйтерсең ак чәчәк бәйләме.
Күңелдә яңа җыр ухта
Ел саен туган көн бәйрәме.


Яшәгез һәрвакыт елмаеп,
Борчулар кермәсен күңелгә.
Бәхетегез кояш нуры сипсен,
Сүрелми гомергә-гомергә.



*Йолдызлар фаразы*

**Кәҗәмөгез**
**(22.12 – 20.01)**

Бөтен ел әйләнәсе эшегездә белемегез һәм осталыгыгыз белән ялтырарсыз. Шуның бәрабәренә әйбәт акча да алып торырсыз. Көчегезгә ышанганлык, үҗәтлек һәм дә саклык хезмәттәшләрегезнең күз алдында үзегезне чын мәгънәсендә профессионалга әйләндереп куячак. . Гомумән, ел уңышлы булачак. Көзен иске дусларыгыз һәм шулар белән бергә көптәнге планнарыгыз кире кайтачак.




*Гыйнварларга тагын керәбез лә...*
*Гыйнвар ае — ап-ак кар төсле.*
*Гыйнвар карларының аклыгында*
*Бераз гына тылсым бар төсле...*

*Гыйнвар – елның иң салкын ае, кыш түбәсе. «Җылы гыйнвардан Аллаһ сакласын», – дигәннәр. Бу аңлашыла да, җылы һәм кар әз икән, димәк, мул уңыш көтмә. Әмма салкын гыйнварлар рәттән кабатланмый. Әгәр бу ай узган ел җылы булган икән, быел суык киләчәк. Гыйнварда якты көн 1,5 сәгатькә озына.*

*Үтеп бара әнә*
*Гыйнвар бабай,*
*Кар өстеннән шыгыр-шыгыр атлап.*
*Сакалларын җилләр җилфердәтә,*
*Керфекләрен бәсләр сарган ап-ак.*
*Як-ягына борылып карамый ул,*
*Уе бик тә еракларга киткән.*
*Иңнәренә аның карлар булып*
*Шыбыр-шыбыр йолдыз ява күктән.*
*Бара гыйнвар горур гына атлап,*
*Адымнары авыр һәм дә салмак.*
*Сакчылары боз-сөңгеләр тотып*
*Як-ягыннан бара аны саклап.*

*Фәнис Яруллин*

# Халкым җәүһәрләре



Беренче гыйнварда көн җылы булса, арыш уңар; җил булса, тары уңар; томан булса, солы уңар.

Ел башы буласы төнне кичен һәр ашлыкның саламын кар астына куеп, бер атнадан алып кара: кайсы ашлыкның саламы бүрткән, озын булса - шуны күбрәк чәчәргә кирәк.

Алтынчы гыйнварда салкын булса, урак вакытында бик эссе булыр. Әгәр җылы булып, кар яуса, һәр ашлык уңар. Әгәр ябалак кар яуса, борчак белән чикләвек уңар.

## Суык бабай

Кызу вакыт Суык бабаемның,
Җил канатлы аты йөгерә.
Боз бизәкле купшы пумаласын
Ак буяуга манып өлгерә.
Тәрәзләргә ап-ак челтәр бизәк,
Агачларга чуклы шәл элгән.
Басу-кырлар йомшак ак
мамыктан
Җем-җем иткән ак толып
кигән.
Елга-күлнең бозлы көзгесенә
Кар бөртеге кунып бизәнә.
Урмандагы зифа, гүзәл чыршы
Яңа елны көтеп төзәнә.
Суык бабаем да бәйрәм көтә,
Әзерләнә кышкы бәйрәмгә.
Ак бизәккә бизи табигатьне,
Калдырырлык итеп хәйранга.



## “Беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар"

**Горизонталь буенча**

**1.** Күлдә үсә.
**5.** Аның белән чәч тарыйбыз.
**6.** Яңа елда кыш бабай белән бергә килә.
**7.** Ай белән..

**Вертикаль буенча**

**1.**"Озеро" сүзен татар теленә тәрҗемә итегез.
**2.** Республикабызның рәисе
**3.**Туган көндә, бәйрәмнәрдә кабартабыз.
**4.**Төс.

